| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ ТУЕМБАШСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КУКМОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ТУЕМБАШ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

с.Туембаш

«22» март, 2024 ел № 8

Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Челны авылы торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Челны торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 27 ноябрендәге 1 номерлы Челны авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Туембаш авыл җирлеге Уставы нигезендә, Туембаш авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елның 7 апреленә 14 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Челны торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 27 ноябрендәге 1 номерлы Челны авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеның беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Челны авылы, Хази Закирова урамы, 1а адресында урнашкан Чуллы авылы клубы бинасында уздырырга.

2. 2024 елның 7 апреленә 16 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Челны торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 27 ноябрендәге 1 номерлы Челны авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеның икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Челны авылы, Хази Закирова урамы, 1а адресында урнашкан Чуллы авылы клубы бинасында уздырырга.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Туембаш авыл җирлеге Чуллы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, махсус хәрби операциясендә катнашкан контракт хезмәте хәрбиләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала 1200 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган

акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Чуллы авылы юлларын вак таш җәеп төзү, ремонтлау һәм төзекләндерү , проект-смета документлары хәм техник күзәтүне гамәлгә ашыру;

- вак таш сатып алу;

- Чуллы авылының урам юл челтәрен тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, проект-смета документлары;

-Чуллы авылының сууткәргеч челтәрләрен, су суырту манараларын төзү, ремонтлау, су саклау зоналарын төзекләндерү, проект-смета документалары;

- Чуллы авылы чишмәләрен төзекләндерү, проект-смета документлары;

- Чуллы авылы урамнарын яктыртуны карап тоту һәм урнаштыру, урамны яктырту өчен светодиодлы лампалар һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары;

- территорияне төзекләндерү?»

2023 елның 27 ноябрендәге 1 номерлы карарында күрсәтелгән эш төрләрен үзгәртү өлешендә түбәндәге эшләр белән:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Чуллы авылы юлларын вак таш җәеп төзү, ремонтлау һәм төзекләндерү , проект-смета документлары хәм техник күзәтүне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, Чуллы авылының урам юл челтәрен тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, проект-смета документлары),

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау (Чуллы авылының сууткәргеч челтәрләрен, су суырту манараларын төзү, ремонтлау, су саклау зоналарын төзекләндерү, проект-смета документалары),

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү (Чуллы авылы чишмәләрен төзекләндерү, проект-смета документлары),

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Чуллы авылы урамнарын яктыртуны карап тоту һәм урнаштыру, урамны яктырту өчен светодиодлы лампалар һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары),

- торак пункт территориясен төзекләндерү ( территорияне төзекләндерү)»?

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Туембаш авыл җирлеге башлыгы И.Ф.Гарипов

ОГРН 1021607753331
ИНН 1623003900